**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «29» февраленнән № 79

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Вәзгыять үзәген төзү һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Вәзгыять үзәге турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 14 апрелендәге 85 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында, Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарында, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасының бүленгән вәзгыять үзәгенә керүче оешмаларда эшләүче вәзгыять үзәкләрен функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру, норматив хокукый тәэмин итүгә типлаштырылган таләпләр стандартын һәм Татарстан Республикасының бүленгән вәзгыять үзәгенә керүче вәзгыять үзәкләрен аккредитацияләү турындагы нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 02 октябрендәге 894 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасында бүленгән вәзгыять үзәкләре челтәрен булдыру буенча чараларны тормышка ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Вәзгыять үзәген төзү һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Вәзгыять үзәге турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 14 апрелендәге 85 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 2 нче абзац өстәргә:

Әлеге карарга кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Вәзгыять үзәге эшчәнлеге турында хисап формасын расларга.»

2) 3 пунктта «икътисад» сүзеннән соң «һәм муниципаль заказ» сүзләрен өстәргә.

3) 4 пунктта:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча)» сүзләренә алмаштырырга;

«икътисад» сүзеннән соң «һәм муниципаль заказ» сүзләрен өстәргә.

4) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6. Таблица нигезендә мәгълүмати-аналитик модельләрне җаваплылык үзәге буларак бүлекчәләргә беркетергә:

| Мәгълүмати-аналитик модель исеме | Бүлекчәнең исеме (җаваплылык үзәге) | ешлык |
|---|---|---|
| Тулаем территориаль продуктка кече эшмәкәрлек субъектларының йогынтысын бәяләү | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм муниципаль заказ бүлеге, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы эшмәкәрләренең Иҗтимагый советы (килешү буенча) | Еллык |
| Җирле бюджетның өстәмә керемнәрә хезмәт хакын минималь хезмәт хакы күләменә җиткерүнең тәэсирен бәяләү | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм муниципаль заказ бүлеге, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы (килешү буенча) | Квартал саен |
| Кече бизнесның хуҗалык итүче субъектларына чагыштырма анализ | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм муниципаль заказ бүлеге | квартал саен |
| Җирле бюджетка физик затларның керемнәренә салым (НДФЛ) күчерү нормативын фаразлау | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы (килешү буенча) | Еллык |

5) 8 пунктта «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча)» сүзләренә алмаштырырга;

6) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Вәзгыять үзәге турында нигезләмәнең 1 бүлегенең 1.2 пунктындагы 7 абзацында «икътисад» сүзеннән соң «һәм муниципаль заказ» сүзләрен өстәргә.

7) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Вәзгыять үзәге турында нигезләмәнең 2 бүлегенең 2.3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты аппаратлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе» сүзләренә алмаштырырга.

8) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Вәзгыять үзәге турында нигезләмәнең 4 бүлегенең 4.1. пунктында «икътисад» сүзеннән соң «һәм муниципаль заказ» сүзләрен өстәргә.

9) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Вәзгыять үзәге турында нигезләмәнең 4 бүлегенең 4.2. пунктында «мәгълүматлаштыру бүлеге тарафыннан» сүзләрен «мәгълүмат белән тәэмин итү һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы секторы тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «29» февралендәге
79 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Вәзгыять үзәге эшчәнлеге турында хисап формасы

1 бүлек. Гомуми мәгълүмат

Әлеге бүлектә текст форматында түбәндәге мәгълүмат чагыла:

мөрәҗәгать иткән кулланучылар саны, шул исәптән тышкы;

заказчыларын күрсәтеп әзерләнгән аналитик материалларның саны турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Вәзгыять үзәге эшенә кыскача характеристикасын күрсәткән дәгъвалар булу (булмау) (алга таба - ТР Яңа Чишмә МР Вәзгыять үзәге).

2 бүлек. Вәзгыять үзәге эше турында җыелма мәгълүмат

| Мәгълүмати ресурсларга, мәгълүмати-аналитик модельләргә, ТР Яңа Чишмә МР Вәзгыять үзәгенең мәгълүмати | ТР Яңа Чишмә МР Вәзгыять үзәгенең мәгълүмати- | Кирәклек турында белешмәләр(авторизацияләнгән запрослар саны, шул исәптән уникаль) | Мәгълүмат ресурсларын формалаштыру һәм | Мәгълүмати ресурслар реестрындагы үзгәрешләр |
|---|---|---|---|---|

| системаларына мөрәҗәгатьләр саны | | аналитик модельләрен кулланып формалаштырылган аналитик материаллар саны | | | | актуальләштерү регламентын үтәү | турында мәгълүмат / ТР Яңа Чишмә МР Вәзгыять үзәгенең мәгълүмат-аналитик модельләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| эчке кулланучылар | тышкы кулланучылар | | мәгълүмати ресурсларны | мәгълүмати-аналитик модельләр | мәгълүмати системаларны | | |
| 1 | 2 | 3 | 4* | 5* | 6* | 7* | 8* |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

* 4,5,6 п. - кирәкле булмаган мәгълүмат ресурслары, мәгълүмати-аналитик модельләр, мәгълүмат системалары турында мәгълүмат;

7 п. - мәгълүмати ресурсларны паспортта күрсәтелгәне нигезендә актуальләштерүнең периодик үтәлеше турында мәгълүмат;

8 п. - ерактан һәм яңа кертелгән мәгълүмати-аналитик модельләрнең исемнәре һәм кодлары (яңаларын кертү, ихтыяҗ булмаганнарны төшереп калдыру).

3 бүлек. ТР Яңа Чишмә МР Вәзгыять үзәге элементларын куллану (ачыкланган өстенлекләрне һәм җитешсезлекләрне күрсәтеп) һәм алга таба үсеш буенча тәкъдимнәр.